| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.01.2022 г.Казань № 52

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2022 елның 9 мартында 8945 номеры белән теркәлде

Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 санлы Россия Федерациясе Законы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы федераль закон нигезендә боерык бирәм:

Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (кушымтада бирелә) расларга.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2022 елның 27 гыйнварындагы
52 санлы боерыгы белән расланды

**Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып эш бирүчеләр яки аларның вәкаләтле вәкилләре (алга таба – эш бирүче) тора.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт оешмалары (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге) тарафыннан күрсәтелә.

1.4. Дәүләт хезмәте, халыкның мәшгульлек үзәге урнашкан урын, аның эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм республиканың «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Татарстан Республикасы порталы) урнаштырылган.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган органнарның (оешмаларның) исемнәре турындагы белешмәләр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында (www.mtsz.tatarstan.ru) урнаштырылган. Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотучы вазыйфаи затлар турында мәгълүмат әлеге Регламентның (белешмәлек) кушымтасында китерелгән.

1.6. Халыкның мәшгульлек үзәкләре шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш көн саен эшли. Эш сәгатьләре халыкның мәшгульлек үзәгенең Эчке тәртип кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы – шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен, халыкның мәшгульлек үзәгенең эш сәгатьләрендә.

1.7. Дәүләт хезмәте, шулай ук халыкның мәшгульлек үзәге урнашкан урын, аның белешмә телефоннары, электрон почта адресы һәм эш графигы турында

мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) халыкның мәшгульлек үзәге бинасында урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында дәүләт хезмәте күрсәтү турында булган белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Министрлыкның (http://www.mtsz.tatarstan.ru), халыкның мәшгульлек үзәгенең рәсми сайтында. Министрлыкның һәм халыкның мәшгульлек үзәгенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

Татарстан Республикасы порталында (http://www.uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал);

«Работа в России» мәшгульлек һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм санлы платформасында (http://www.trudvsem.ru) (алга таба – Бердәм санлы платформа);

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында, Бердәм санлы платформада «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат эш бирүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү чорлары һәм тәртибе турында мәгълүмат алу эш бирүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, эш бирүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла;

3) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләргә (алга таба – КФҮ) һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыннарына (алга таба – ерактагы эш урыны) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка, халыкның мәшгульлек үзәгенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

5) Министрлыкка, халыкның мәшгульлек үзәгенә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә (mtsz@tatar.ru).

1.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитларын һәм аларның рәсми басылып чыгу чыганакларын да күрсәтеп) Интернетта Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.9. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- КФҮ – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торган), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ санлы федераль закон) таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы яки шәһәр округы шәһәр (авыл) җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки вәкаләтле вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, КФҮ, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты, КФҮ хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ санлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмалар яки аларның хезмәткәрләре тарафыннан мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдаланганда аның бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе;

- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

- БИАС – электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итүче инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) 210-ФЗ санлы федераль законның 2 статьясының 3 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла. Гариза рәвеше Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле документларның рәвешләрен раслау турында» 2021 елның 20 октябрендәге 738н санлы боерыгы (алга таба - 2021 елның 20 октябрендәге 738н санлы боерык) белән расланган.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү.

## 2.2. Башкарма хакимият органы (оешма) атамасы

Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре күрсәтә.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләрне сайлау өчен Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрыннан өземтә рәвешендә гражданнар кандидатуралары исемлеген бирү (җибәрү) тора.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән эш бирүчегә бирелә (җибәрелә):

кәгазь чыганакта эш бирүчегә шәхсән;

электрон документ рәвешендә электрон почта адресы, Бердәм санлы платформа буенча;

2.3.3. Эш бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге очракларда туктатыла:

халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча тиешле буш эш урыннары (буш вазыйфалар) биләнә торган булу сәбәпле;

эш бирүчедән тиешле буш эш урыннарын (вакантлы вазыйфаларны) мөстәкыйль рәвештә тәэмин итү турында белешмәләр алганнан соң;

эш бирүченең халыкның мәшгульлек үзәге белән хезмәттәшлек итүдән баш тартуы сәбәпле.

## 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Эш бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән эш бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкин булган иң күп вакыты 20 минуттан артмаска тиеш.

Эш бирүче алга таба мөрәҗәгать иткән очракларда дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь рөхсәт ителгән вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.4.2. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү (җибәрү) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

## 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән эш бирүче, 2021 елның 20 октябрендәге 738н санлы боерык белән расланган үрнәк буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирә, 2021 елның 20 октябрендәге 738н санлы боерык белән расланган үрнәк буенча эш урыны турында мәгълүмат терки һәм түбәндәгеләрне тапшыра:

Россия Федерациясе паспорты яки аны алмаштыра торган документ (эшкә алучы затлар – Россия Федерациясе гражданлыгына ия булган физик затлар өчен);

чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документлар (эшкә алучы затлар – чит ил гражданлыгына ия булган физик затлар өчен);

шәхесне таныклый торган документлар (эшкә алучы затлар – гражданлыгы булмаган физик затлар өчен).

Алга таба мөрәҗәгать иткән очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен эш бирүче эш урыны турында мәгълүмат бирә (җибәрә).

2.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза кәгазен эш бирүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның, халыкның мәшгульлек үзәгенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Порталында, Бердәм санлы платформада урнаштырылган.

2.5.3. Эш бирүчеләргә гариза тапшыру ысулын сайлау мөмкинлеге тәэмин ителә: халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, почта аша, электрон почтаны да кертеп, факсимиль элемтә ярдәмендә яисә гади электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, шул исәптән Татарстан Республикасы порталыннан, Бердәм порталдан, Бердәм санлы платформадан файдаланып, яисә гаризаны күпфункцияле үзәк, читтәге эш урыны аша тапшыру юлы белән.

Эш бирүче күпфункцияле үзәккә, КФҮ ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшыру күпфункцияле үзәк белән халыкның мәшгульлек үзәге арасындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм чорларда, ләкин гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Гади электрон имзаны алу өчен, эш бирүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

## 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм

мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Вәкаләтле органнан (салым хезмәте) ведомствоара электрон багланышлар каналлары буенча юридик затны, шәхси эшкуарны яки крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр алына.

Эш бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларның күчермәләрен үз инициативасы буенча тапшырырга (җибәрергә) хокуклы. Документларның күчермәләре нотариус яки орган (документның оригиналын биргән оешма) тарафыннан раслатмаган очракта, алар оригиналларын күрсәтеп тапшырыла һәм халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан раслана.

2.6.2. Әлеге дәүләт хакимияте органы тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.

2.6.3. Эш бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ санлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ санлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

гаризаның текстын укып булмый;

гариза, шул исәптән электрон документ рәвешендә җибәрелгәне дә, шәхси яки электрон имза белән таныкланмаган;

документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр бар.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентка 5 нче кушымтада билгеләнгән үрнәккә туры китереп рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәгенең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм эш бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне электрон адреска, Бердәм санлы платформадагы шәхси кабинетка җибәрелә.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Халыкның мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән эш бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

буш эш урыннары турындагы мәгълүматны халыкның мәшгульлек үзәгенә турыдан-туры, яисә кушымталар исемлеге белән почта аша юллау рәвешендә яисә, Интернет челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып электрон документлар рәвешендә тапшырылмавы (җибәрелмәве);

шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гражданинның шәхесен яисә гражданлыгын таныклый торган документларның яисә аларны алмаштыра торган документларның булмавы (эш бирүче – физик зат өчен);

юридик затларның (шәхси эшкуарларның, крестьян (фермер) хуҗалыгының) бердәм дәүләт реестрында эш бирүченең дәүләт теркәвенә алынуы турында мәгълүмат булмау, әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан эш бирүче – юридик зат яки шәхси эшкуар буларак гариза бирелгән булса.

Эш бирүче алга таба мөрәҗәгать иткән очракларда, буш эш урыннары турындагы мәгълүматны халыкның мәшгульлек үзәгенә турыдан-туры, яисә кушымталар исемлеге белән почта аша юллау рәвешендә яисә, Интернет челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып электрон документлар рәвешендә тапшырылмавы (җибәрелмәве) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентка 1 нче кушымтада билгеләнгән үрнәккә туры китереп рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә халыкның мәшгульлек

үзегенең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм эш бирүчегә  дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне эш бирүченең электрон адресына, Бердәм санлы платформадагы шәхси кабинетына җибәрелә.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Заруи һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

Эш бирүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте чират тәртибендә күрсәтелә.

Чиратта тору вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты биш минуттан артмаска тиеш.

### 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә дә

2.13.1. Эш бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгате гариза  алынган көнне теркәлә.

Гаризаны теркәү халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (буш эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкы) регистрына эш бирүче тапшырган документларда булган белешмәләрне исәпкә алу язуының теркәү санын беркетеп кертү дигән сүз.

Эш бирүченең үтенече буенча гаризаны кабул итү датасы һәм исәпкә алу язуының теркәү саны турында белешмәләрне үз эченә алган гариза күчермәсе бирелә ала.

2.13.2. Халыкның мәшгульлек үзәгенә Татарстан Республикасы порталы, Бердәм портал, КФҮ, КФҮ ерактагы эш урыны аша электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә алынган гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы киләсе эш көнендә теркәлә.

Күпфункцияле үзәккә, КФҮ ерактагы эш урынына шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза тапшырылган көнне эш бирүчегә гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган теркәү саны һәм электрон гаризаны тапшыру көне белән Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан язу бирелә.

Гариза Татарстан Республикасы порталы, Бердәм портал, Бердәм санлы платформа аша җибәрелгән очракта, эш бирүче гариза биргән көнне электрон почта аша гаризаның җибәрелүен раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәү саны һәм гаризаны тапшыру көне күрсәтелә.

## 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат эш бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.7 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (гариза һәм эш урыны турында мәгълүмат) үрнәкләре урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

гариплеге булган затка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү,

инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

гариплегe булган затларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм язулы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм капма-каршы фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н санлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка сукырларны озата йөри торган этне кертү.

2.14.3. Гариплегe булган затларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеген тудыру өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

гариплегe булган затларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

ишетү буенча гариплегe булган затларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

гариплегe булган затларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм капма-каршы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.14.4. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле

үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ санлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

эш бирүче өчен шәхси яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү рәвешендә (шәхсән кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларын кулланып, массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, мәгълүмат материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү) мәгълүмат алу мөмкинлеге;

мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм чорлары, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында тулы мәгълүмат булуы;

гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытының саклануы;

күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге;

гариплеге булган затларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итү.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләрнең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлеше;

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

халыкның мәшгульлек үзәге белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы.

мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре белән үзара хезмәттәшлек итү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргән очракта, турыдан-туры бәйләнеш таләп ителми.

2.15.3. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә эш бирүченең мәшгульлек үзәге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.4. Дәүләт хезмәте (гаризаны кабул итүдән тыш) күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында күрсәтелми.

2.15.5. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

## 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр

Гаризаны төзү, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка рәвештә тапшыру зарурлыгыннан тыш, гаризаның электрон рәвешен тутыру юлы белән Татарстан Республикасы порталында, Бердәм порталда, КФҮ, КФҮ ерактагы эш урынында гамәлгә ашырыла.

Электрон документ рәвешендәге гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә Интернет челтәреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук эш бирүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә электрон чыганаклардан файдаланып тәкъдим ителә ала. Шул ук вакытта гариза «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ санлы федераль закон (алга таба – 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ санлы федераль закон) һәм 210-ФЗ санлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

Эш бирүче тарафыннан мәшгульлек һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә Бердәм санлы платформада (алга таба – Бердәм санлы платформа) эш урыннары турында мәгълүмат урнаштырылганда һәм халыкның мәшгульлек үзәгенә Бердәм санлы платформа аша мөрәҗәгать иткән очракта, эш бирүче һәм эш урыны турындагы мәгълүмат автомат тәртибендә Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына эләгә.

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны (гамәлләрне) дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

эш бирүчене консультацияләү, эш бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү;

эш бирүче алга таба мөрәҗәгать иткән очракларда кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү;

ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

эш бирүчегә электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү;

Техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.2. Эш бирүчене консультацияләү, эш бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә

Эш бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тупланма өлеше, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, һәм эш бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әгәр эш бирүче мөрәҗәгатькә язмача җавап алырга тели икән, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тупланма өлеше, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, язмача консультация бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура эш бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Эш бирүче КФҮ, ерактагы эш урынына шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша дәүләт хезмәте күрсәтү, гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү, халыкның мәшгульлек үзәгенә гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны җибәрү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.3.1. Күпфункцияле үзәк белгече эш бирүчене дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, рәвеше буенча һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза кәгазен тутырганда ярдәм күрсәтә.

Эш бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк http://mfc16.tatarstan.ru/ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

3.3.2. Эш бирүче шәхсән яисә вәкаләтле вәкил аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.3.3. КФҮ белгече гаризаны мәшгульлек үзәгенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә халыкның мәшгульлек үзәге һәм

күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек халыкның мәшгульлек үзәге һәм «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе арасында төзелә торган үзара хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең эш бирүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламенты нигезендә җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮ эш регламентында, халыкның мәшгульлек үзәге белән КФҮ арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны КФҮ теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – мәшгульлек үзәгенә юлланган гариза.

3.4. Беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның алынуы административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

3.4.1. Беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә түбәндәге административ гамәлләр башкарыла:

эш бирүче һәм эш урыны турында эш бирүче тәкъдим иткән документлардагы мәгълүматларны анализлау;

эш бирүчегә хезмәт законнары нигезләмәләре, хезмәт өлкәсендә мәҗбүри хезмәт һәм дискриминация хокукы, эш бирүченең хезмәт килешүе төзегәндә хокуклары һәм бурычлары, хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка актларны бозган өчен җаваплылык билгели торган хезмәт законнары нигезләмәләре турында мәгълүмат бирү;

эш урыны турындагы мәгълүматны бирү һәм Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) урнаштыру, халыкның мәшгульлек үзәкләре җибәргән гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү, эш бирүче тарафыннан гражданнарга эшкә алу яки эшкә кабул итүдән баш тарту турында белешмәләрне күрсәтеп, эшкә җибәрелгән юлламаларны рәсмиләштерү ысулын эш бирүче белән килештерү;

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкына) эш бирүче һәм эш урыны турында мәгълүмат кертү;

эш бирүчегә хезмәт функцияләрен үтәүгә (билгеле бер һөнәр (белгечлек) яки вазыйфа буенча эшкә), һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсенә, вакансияләр турында мәгълүматта булган тәҗрибә һәм эш күнекмәләренә карата таләпләрне исәпкә алып, Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (алга таба – Физик затлар регистры) үзләренең шәхси мәгълүматларын эш бирүчегә тапшырырга ризалык белдергән гражданнар турында белешмәләр булган очракта, кирәкле хезмәткәрләрне сайлау;

эш бирүче белән гражданнарның кандидатураларын килештерү;

кирәкле хезмәткәрләр булмаган очракта, эш бирүчегә катнаш һөнәрләргә (белгечлекләргә) ия булган яисә башка җирлектә яши торган гражданнар кандидатураларын тәкъдим итү;

кирәкле хезмәткәрләрне мөстәкыйль сайлап алу өчен, эш бирүче таләпләренә туры килә торган Физик затлар регистрындагы гражданнар кандидатуралары исемлеген (алга таба – гражданнар кандидатуралары исемлеге) эш бирүчегә тәкъдим итү;

кирәкле хезмәткәрләр булмаган очракта, эш бирүчегә түләүле иҗтимагый эшләр оештыру, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, вакансияләр һәм уку урыннары ярминкәләрендә катнашу турында тәкъдим итү;

административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү нәтиҗәләрен Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкы) регистрына кертү.

3.4.2. Эш бирүче һәм эш урыны турында эш бирүче тәкъдим иткән документлардагы мәгълүматларны анализлау

Административ процедураны үти башлау өчен эш бирүченең эш урыны мәгълүмат буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасының булуы нигез булып тора.

Гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә почта аша, электрон почтаны да кертеп, факсимиль элемтә ярдәмендә яисә электрон документ рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы порталыннан, Бердәм санлы платформадан файдаланып тапшырылган очракта яисә гариза КФҮ, КФҮ ерактагы эш урыны аша җиткерелгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза алынган көннән соң киләсе эш көненнән соңга калмыйча эш бирүче белән шәхсән кабул итү вакытын, көнен килештерә, шулай ук аңа әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру зарурлыгы турында мәгълүмат җиткерә.

Шәхси кабул итү барышында халыкның мәшгульлек үзәге белгече дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булуы яисә булмавына карата документларны тикшереп чыга.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге эш бирүчегә баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта:

кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча эш бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны кабул итә (кирәк булса, гаризан тутырырга ярдәм итә);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларның булу-булмавын тикшерә;

Эш бирүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырылган документлар нигезендә әлеге Регламентның 2.8 пунктында билгеләнгән нигезләр буенча дәүләт хезмәте күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, халыкның мәшгульлек үзәге баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен аңлата, әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә, 2 нөсхәдә язма рәвештә баш тарту турында карар рәсмиләштерә, аларның берсе халыкның мәшгульлек үзәгендә кала, икенчесе эш бирүчегә бирелә.

Үтәү вакыты: процедуралар дүрт минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында язмача хәбәр итү һәм эш бирүчегә кире кайтарылган документлар, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдән язмача баш тартуы.

3.4.3. Эш бирүчегә Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы закон нигезләмәләре турында мәгълүмат бирү

Эш бирүченең халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүе административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчегә түбәндәгеләр хакында мәгълүмат җиткерә:

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, документлар белән расланган (әлеге Регламентта каралган документларны тапшырган) очракта, гаризадагы белешмәләрнең исәпкә алынуы турында;

эш бирүченең хокуклары һәм бурычларын үз эченә алган, халыкны эш белән тәэмин итүдә катнашкан вакытта эш бирүченең хокукларын һәм бурычларын билгели торган Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы закон нигезләмәләре, хезмәт хокукын билгели, мәҗбүри хезмәтне һәм хезмәт өлкәсендәге дискриминацияне тыя, хезмәткәр белән хезмәт килешүен төзегән вакытта эш бирүченең хокукларын һәм бурычларын һәм хезмәт законнарын һәм хезмәт хокуклары нормаларын үз эченә алган башка актларны бозган өчен җаваплылыкны билгели торган хезмәт законнары нигезләмәләре турында.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң ике минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүчегә хезмәт законнары нигезләмәләре турында мәгълүмат бирү.

3.4.4. Эш урыны турындагы мәгълүматны бирү һәм Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) урнаштыру, халыкның мәшгульлек үзәкләре җибәргән гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү, эш бирүче тарафыннан гражданнарга эшкә алу яки эшкә кабул итүдән баш тарту турында белешмәләрне күрсәтеп, эшкә җибәрелгән юлламаларны рәсмиләштерү ысулын эш бирүче белән килештерү

Эш бирүченең халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм эш урыны турында мәглүмат булуы турында гариза белән мөрәҗәгать итүе административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Үзләре турындагы белешмәләр Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) булган эш бирүчеләр өчен эш урыны турындагы мәгълүматны почта элемтәсе аша җибәрү, телефон буенча мөрәҗәгать итү (алга таба кәгазь чыганакта раслап), факсимиль элемтә чараларын кулланып яисә электрон документ рәвешендә, шул исәптән Бердәм санлы платформадан яисә Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ санлы федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә файдаланылуы рөхсәт ителә торган электрон имза төрләре турында» 2012 елның 25 июнендәге 634 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән раслап, мәгълүмат тапшыру мөмкинлеге тудырыла.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүче белән түбәндәге ысулларны килештерә:

эш урыны турында мәгълүмат җиткерү (халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килү, телефон, почта аша, электрон почтаны да кертеп, факсимиль элемтә ярдәмендә яисә электрон документ рәвешендә, шул исәптән Бердәм санлы платформадан яисә Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып);

эш урыны турында мәгълүмат урнаштыру (территориаль, территориальара, федераль дәрәҗәләрдә, массакүләм мәгълүмат чараларында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы башка халыкның мәшгульлек үзәкләренең Интернет-ресурсларында);

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан җибәрелгән гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү, гражданнарга бирелгән эш юлламаларын, эшкә кабул итү яки эшкә алудан баш тарту турындагы мәгълүматларны күрсәтеп, рәсмиләштерү (халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килеп, телефон аша, почта аша, электрон почтаны да кертеп, факсимиль элемтә ярдәмендә).

Эш бирүче эш урыны турындагы мәгълүматны бирү һәм Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) урнаштыру, халыкның мәшгульлек үзәге җибәргән гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү, эш бирүче тарафыннан гражданнарга эшкә алу яки эшкә кабул итүдән баш тарту турында белешмәләрне күрсәтеп, эшкә җибәрелгән юлламаларны рәсмиләштерү ысулын сайлый.

Әлеге пунктның дүртенче, бишенче, алтынчы, җиденче, сигезенче кызыл юлларында билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш урыны турында мәгълүмат бирү һәм урнаштыру, гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү, гражданнарга бирелгән эш юлламаларын, аларны эшкә алу яки эшкә кабул итүдән баш тарту турында белешмәләр күрсәтеп, рәсмиләштерү ысулын сайлау.

3.4.5. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкына) эш бирүче һәм эш урыны турында мәгълүмат кертү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече дәүләт хезмәте күрсәтү һәм эш урыны турындагы мәгълүмат буенча гариза нигезендә эш бирүчене, исәпкә алу язуы санын теркәп, эш бирүче тарафыннан тапшырылган документларда булган мәгълүматларны Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затларның электрон регистрына (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкына) кертү юлы белән терки.

Эш бирүче Бердәм санлы платформада үзе урнаштырган эш урыннары турындагы мәгълүмат нигезендә, халыкны эшбелән тәэмин итү өлкәсендә Бердәм санлы платформадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән очракта, эш бирүче турындагы мәгълүмат, шулай ук эш урыны турындагы мәгълүмат автомат тәртибендә Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затларның электрон регистрына (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкына) эләгә.

Эш бирүченең үтенече буенча гаризаны кабул итү датасы һәм исәпкә алу язуының теркәү саны турында белешмәләрне үз эченә алган гариза күчермәсе бирелә ала.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң ике минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче һәм буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында мәгълүматларны Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затларның электрон регистрына (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкына) кертү.

3.4.6. Эш бирүчегә хезмәт функцияләрен үтәүгә (билгеле бер һөнәр (белгечлек) яки вазыйфа буенча эшкә), һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсенә, вакансияләр турында мәгълүматта булган тәҗрибә һәм эш күнекмәләренә карата таләпләрне исәпкә алып, үзләренең шәхси мәгълүматларын эш бирүчегә тапшырырга ризалык белдергән гражданнар турында белешмәләр булган очракта, кирәкле хезмәткәрләрне сайлау

Эш урыны турындагы мәгълүмат нигезендә халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләрнең кандидатураларын сайлый, эш бирүчегә шәхси мәгълүматларын тапшырырга ризалык белдергән гражданнарның шәхси мәгълүматларын үз эченә алган гражданнар кандидатуралары исемлеген бастырып чыгара һәм эш бирүчегә тәкъдим итә (Физик затлар регистрында эш бирүче таләпләренә туры килә торган хезмәткәрләр булган очракта) (алга таба – Физик затлар регистрыннан өземтә).

Эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләрне сайлау хезмәт функциясен (билгеле бер һөнәр (белгечлек), квалификация яки вазыйфа буенча эшне) үтәүгә, хезмәткәр кандидатурасына, аның һөнәри әзерлеге һәм квалификациясе дәрәҗәсенә, эш тәҗрибәсе һәм күнекмәләренә карата таләпләрне, шулай ук гражданнарның шәхси мәгълүматларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң дүрт минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче тарафыннан гражданнарның шәхси мәгълүматларын үз эченә алган кандидатуралар исемлеген алу, яисә эш бирүчегә туры килә торган кандидатураларның булмавы турында хәбәр итү.

3.4.7. Эш бирүче белән гражданнарның кандидатураларын килештерү

Физик затлар регистрыннан өземтә административ гамәлләрне үти башлау өчен нигез булып тора.

Эш бирүче Физик затлар регистрыннан тәкъдим ителгән өземтәдән гражданнар кандидатураларын сайлый һәм сайлап алынган кандидатураларны әңгәмәгә җибәрүгә үз ризалыгын белдерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында эш бирүчегә телефон яки видеоэлемтә аша, Интернет челтәрен кулланып әңгәмә үткәрү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

гражданинга телефон аша эш урыны (вакантлы вазыйфа) һәм гражданин белән әңгәмә уздыруга ризалыгын белдергән эш бирүче турында мәгълүмат җиткерә;

эш бирүчегә гражданин белән әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү, гражданинга бирелгән юлламаны рәсмиләштерү зарурлыгы турында хәбәр итә.

Әлеге пунктның өченче, дүртенче, бишенче, алтынчы, җиденче кызыл юлларында билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң өч минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче тарафыннан Физик затлар регистрыннан тәкъдим ителгән өземтәдән туры килә торган хезмәткәр кандидатурасын сайлап алу.

3.4.8. Кирәкле хезмәткәрләр булмаган очракта, эш бирүчегә катнаш һөнәрләргә (белгечлекләргә) ия булган яисә башка җирлектә яши торган гражданнар кандидатураларын тәкъдим итү

Физик затлар регистрыннан өземтә административ гамәлләрне үти башлау өчен нигез булып тора.

Кирәкле хезмәткәрләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчегә катнаш һөнәрләргә (белгечлекләргә) ия булган яисә башка җирлектә яши торган гражданнарның кандидатураларын тәкъдим итә.

Катнаш һөнәрләргә (белгечлекләргә) ия булган яисә башка җирлектә яши торган хезмәткәрләрне сайлау, шулай ук эш бирүче белән әлеге гражданнарның кандидатураларын килештерү халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан әлеге Регламентның 3.4.6 пунктчасында каралган гамәлләр эзлеклелеге нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: катнаш һөнәргә ия булган хезмәткәрне сайлау.

3.4.9. Үзләре турындагы белешмәләр эш бирүченең хезмәткәр кандидатурасына карата таләпләренә туры килгән Физик затлар регистрыннан өземтәдәге гражданнар кандидатуралары исемлеген, кирәкле хезмәткәрләрне мөстәкыйль сайлап алу өчен, эш бирүчегә тәкъдим итү

Физик затлар регистрыннан өземтәдә гражданнар кандидатураларының булуы административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Физик затлар регистрында эш бирүче таләпләренә туры килә торган граждан кандидатуралары булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчегә үзләренең шәхси мәгълүматларын тапшыруга ризалык белдергән гражданнарның

шәхси мәгълүматларын үз эченә алган гражданнар кандидатуралары исемлеген бастырып чыгара һәм, хезмәткәрләрне мөстәкыйль сайлап алу өчен, аны эш бирүчегә тәкъдим итә.

Эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләрне сайлау хезмәт функциясен (билгеле бер һөнәр (белгечлек), квалификация яки вазыйфа буенча эшне) үтәүгә, хезмәткәр кандидатурасына, аның һөнәри әзерлеге һәм квалификациясе дәрәҗәсенә, эш тәҗрибәсе һәм күнекмәләренә карата таләпләрне, шулай ук гражданнарның шәхси мәгълүматларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче тарафыннан шәхси мәгълүматлар тупланган гражданнар кандидатуралары исемлеген алу.

3.4.10. Кирәкле хезмәткәрләр булмаган очракта, эш бирүчегә түләүле иҗтимагый эшләр оештыру, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, вакансияләр һәм уку урыннары ярминкәләрендә катнашу турында тәкъдим итү

Физик затлар регистрыннан өземтәдә гражданнар кандидатураларының булмавы административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда ярдәм итү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәткәндә эш бирүчегә халыкның мәшгульлек үзәге оештыра торган эш белән тәэмин итү актив сәясәтенең түбәндәге чараларында катнашырга тәкъдим итә ала:

вакантлы эш һәм укыту өчен эш урыннары ярминкәсе;

түләүле иҗтимагый эшләр;

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарны укудан буш вакытларында вакытлыча эшкә урнаштыру;

18 яшьтән 25 яшькә кадәр, урта һөнәри белем яисә югары белем алган һәм белем һәм квалификация турында документ бирелгән көннән алып ел дәвамында эш эзләүче гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру;

эш эзләгәндә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру.

Эш бирүченең эш урыннары һәм укыта торган эш урыннары ярминкәсендә катнашырга ризалыгы булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчегә әлеге чараны үткәрү көне, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә.

Эш бирүченең халыкның мәшгульлек үзәге оештыра торган актив эш белән тәэмин итү сәясәте чараларында катнашу ризалыгы булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчене кирәкле мәгълүмат алу өчен мәшгульлекнең актив сәясәт чараларын оештыру функциясен башкаручы белгечкә җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан оештырыла торган актив мәшгульлек сәясәте (түләүле җәмәгать эшләрен оештыру, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, вакантлы эш һәм укыту өчен урыннары ярминкәләрендә катнашу) чараларында катнашу турында тәкъдим алу.

3.4.11. Административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү нәтиҗәләрен Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкы) регистрына кертү

Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан әлеге Регламентның 3.4.4-3.4.10 пунктларында күрсәтелгән карарларны кабул итү административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Эш бирүче халыкның мәшгульлек үзәгенә әңгәмә уздыру нәтиҗәләре яисә хезмәткәр кандидатурасын ирекле эш урынын (вакантлы вазыйфаны) биләү өчен карау турындагы мәгълүматны җиткерә һәм, гражданинны эшкә алган очракта, биш көндек чорда, эшкә алу көнен күрсәтеп, эшкә юлламагы халыкның мәшгульлек үзәгенә кайтара.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкында) түбәндәгеләрне терки:

эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен (гражданнар турында мәгълүмат булган гражданнар кандидатуралары исемлеген алу, вакансияне тутыру турында мәгълүмат кертү);

эш бирүчене актив мәшгульлек сәясәте чараларында катнашу өчен җибәрү фактын.

Үтәү вакыты: процедура мәгълүмат алу көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: әңгәмә нәтиҗәсен теркәү яисә эш бирүче тарафыннан буш эш урынын (вакантлы вазыйфаны) биләп торуга хезмәткәр кандидатурасын карау.

3.5. Эш бирүче алга таба мөрәҗәгать иткән очракларда кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның алынуы административ процедура үтәлешен башлау нигезе булып тора.

3.5.1. Эш бирүче алга таба мөрәҗәгать иткән очракларда, эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә түбәндәге административ гамәлләр башкарыла:

хезмәткәрләргә ихтыяҗ турында мәгълүматларның булу-булмавын тикшерү;

эш бирүче тарафыннан бирелә торган мәгълүмат белән танышу:

- гражданнар кандидатуралары исемлеген карау нәтиҗәләре турында;

- халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан җибәрелгән гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре турында;

- түләүле иҗтимагый эшләр оештыру, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, вакансияләр һәм уку урыннары ярминкәләрендә катнашу карары турында;

кирәкле хезмәткәрләрне сайлау билгеләрен аныклау;

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкына) хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турында мәгълүмат кертү;

әлеге Регламентның 3.4.1 пунктындагы бишенче-унберенче кызыл юлларында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) гамәлгә ашыру.

3.5.2. Хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турында мәгълүматларның булу-булмавын тикшерү

Административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып элек эш бирүче тарафыннан тәкъдим ителгән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм эш урыны турында мәгълүмат алынуы тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турында әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган белешмәләр булуын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында билгеләнгән нигезләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Эш урыны турындагы мәгълүмат эш бирүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә почта аша, шул исәптән электрон почта аша, факсимиль элемтә ярдәмендә җибәрелергә мөмкин.

Эш урыны турындагы мәгълүмат, алга таба ул кәгазьдә расланган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан телефон аша кабул ителергә мөмкин.

Эш урыны турында мәгълүмат башлангыч рәвештә Бердәм санлы платформада урнаштырылырга мөмкин.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булып, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен аңлата, әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә, 2 нөсхәдә язма рәвештә баш тарту турында карар рәсмиләштерә, аларның берсе халыкның мәшгульлек үзәгендә кала, икенчесе эш бирүчегә бирелә.

Үтәү вакыты: процедура бер минут эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар яисә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдән язмача баш тартуы.

3.5.3. Эш бирүче тарафыннан бирелә торган мәгълүмат белән танышу

Административ гамәлне үти башлау өчен әлеге Регламентның 2.8 пункты нигезендә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан эш бирүчегә дәүләт ярдәме күрсәтү турында карар кабул ителүе нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүче тарафыннан түбәндәгеләр турында тапшырылган мәгълүмат белән таныша:

гражданнар кандидатуралары исемлеген карау нәтиҗәләре турында;

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан җибәрелгән гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре турында;

түләүле иҗтимагый эшләр оештыру, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, вакансияләр һәм уку урыннары ярминкәләрендә катнашу карары турында.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүченең гражданнар кандидатуралары исемлеген карау нәтиҗәләре, халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан юлланган гражданнар белән әңгәмә, түләүле җәмәгать эшләрен оештыру, эш эзләүдә

кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, эш урыннары һәм укыта торган эш урыннары ярминкәләрендә катнашу турындагы мәгълүмат белән танышып чыгуы.

3.5.4. Кирәкле хезмәткәрләрне сайлау билгеләрен ачыклау

Эш урыны турында тәкъдим ителгән мәгълүмат нигезендә халыкның мәшгульлек үзәге белгече, эш бирүче тарафыннан бирелгән документлардагы мәгълүматларны исәпкә алып, кирәкле хезмәткәрләрне сайлау билгеләрен ачыклый, эш бирүче белән мәгълүмат алмашу ысулын, гражданнар кандидатураларын җибәрү тәртибен һәм дәүләт хезмәте күрсәтү фактын раслау тәртибен килештерә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кирәкле хезмәткәрләрне сайлау билгеләрен ачыклау.

3.5.5. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкына) хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турында мәгълүмат кертү

Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан әлеге Регламентның 3.5.2-3.5.4 пунктларында күрсәтелгән карарларны кабул итү административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкына) эш урыны турындагы мәгълүматны кертә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкына) эш бирүче һәм эш урыны турында мәгълүмат кертү.

3.5.6. Әлеге Регламентның 3.4.1 пунктындагы алтынчы-унберенче кызыл юлларында каралган административ процедураларны (гамәлләр) гамәлгә ашыру.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрына (эш урыннары һәм эш бирүчеләр банкына) эш урыны турында мәгълүмат кертү нигезендә халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчегә әлеге Регламентның 3.4.6-3.4.11 пунктчаларында билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге нигезендә гражданнар кандидатураларын сайлап ала.

Үтәү вакыты: процедура эш бирүченең кабат мөрәҗәгать иткән көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләрне сайлау; эш бирүчегә катнаш һөнәрләргә ия булган гражданнар кандидатураларын тәкъдим итү; эш бирүчегә халыкны эш белән тәэмин итүнең актив сәясәте чараларында катнашырга тәкъдим итү.

3.6. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

Административ процедураны гамәлгә ашыру нигезе булып халыкның мәшгульлек үзәгендә әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән мәгълүматның (белешмәләрнең) булмавы тора.

3.6.1. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша юридик затны яки шәхси эшкуарны, яисә крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (документлар) яки юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазен электрон рәвештә җибәрә.

Ведомствоара мөрәҗәгать электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешентә формалаштырыла һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы каналлары буенча җибәрелә.

Ведомствоара электрон мөрәҗәгатьне электрон документ рәвешендә формалаштыру һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы каналлары буенча җибәрүнең техник мөмкинлекләре булмаганда, ведомствоара мөрәҗәгать кәгазьдә почта аша, бер үк вакытта почта аша яисә курьер ярдәмендә җиткерү юлы белән факс буенча җибәрелә.

Ведомствоара мөрәҗәгать 210-ФЗ санлы федераль законның $7^2$ статьясы таләпләре нигезендә формалаштырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураны үтәү вакыты: гаризаны теркәү көнендә.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара электрон рәсми мөрәҗәгать формалаштыру һәм җибәрү.

3.6.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре әлеге Регламентның 3.6.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша алынган рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә соралган белешмәләрне (документларны) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатькә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яисә сорала торган белешмәләрнең булмавы турында халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән хәбәр.

3.7. Эш бирүчегә электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү

Электрон документ рәвешендәге гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә Интернет челтәреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук эш бирүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә электрон чыганаклардан файдаланып тәкъдим ителә ала.

Эш бирүче халыкның мәшгульлек үзәгенә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документ теркәп тапшыра.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә почта аша, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша, электрон почта буенча, Татарстан Республикасы Порталы, Бердәм портал, Бердәм санлы платформа аша алынган гариза мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителгән гариза һәм документларны карау өчен билгеләнгән тәртиптә карала.

Гаризаны электрон формада, шул исәптән мәшгульлек үзәгенең рәсми сайты, Татарстан Республикасы порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гаризаны кәгазьдә бастырып чыгара һәм алынган

көнендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү турындагы гаризаларны теркәү журналында терки.

Гариза электрон формада эшләми торган вакытта алынган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гаризаны кәгазьдә бастырып чыгара һәм алынган көннән соң килгән беренче эш көнендә аны дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналында терки.

3.8. Техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

Эш бирүченең халыкның мәшгульлек үзәге биргән исемлектә (программа продуктыннан өземтәдә) булган хәреф хаталарын һәм ялгышларны төзәтү турында гариза белән халыкның мәшгульлек үзәгенә, КФҮ мөрәҗәгать итүе административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

3.8.1. Техник хата эш бирүче тарафыннан, эш бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 2 нче кушымтасына ярашлы үрнәктә халыкның мәшгульлек үзәгенә эш бирүче тарафыннан гариза бирелгән очракта төзәтелә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм эш бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы);

кирәкле хезмәткәрләрне сайлау өчен гражданнар кандидатуралары исемлеген үзгәртеп рәсмиләштерә;

эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләр сайлау өчен гражданнар кандидатуралары исемлеген үзгәртеп рәсмиләштерү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, кирәкле хезмәткәрләр сайлау өчен гражданнар кандидатураларының үзгәртеп рәсмиләштерелгән исемлеге.

3.8.2. Эш бирүче шәхсән яки вәкаләтле вәкил аша халыкның мәшгульлек үзәге биргән исемлектә (программа продуктыннан өземтәдә) булган хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турында КФҮ язмача гариза бирә ала.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8.3. Халыкның мәшгульлек үзәгенә техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү

Административ процедураны үти башлау өчен техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән мөрәҗәгать нигез булып тора.

Күпфункцияле үзәк белгече халыкның мәшгульлек үзәгебелән күпфункцияле

үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

### 4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Административ регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен башкаруга таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларның җаваплы затлар тарафыннан саклавын һәм үтәлүен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә тикшерүләр уздырудан, Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүдән тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре тарафыннан әлеге Регламентның дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеген һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларны үтәвенә карата агымдагы контрольлек халыкның мәшгульлек үзәге директоры яисә аның вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольлек әлеге Регламентны, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 6 декабрендәге 871н санлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрларына белешмәләрне бирү тәртибен, чорларын һәм рәвешен, шулай ук аларда булган мәгълүмат төрләре исемлеген дә кертеп, Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрын алып бару тәртибен, эш бирүчеләрнең исәпкә алу документлары һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлеген билгели торган башка документларны кәгазьләрен тутыру, алып бару һәм саклауга карата таләпләрне саклау һәм үтәү буенча тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыру вакыты халыкның мәшгульлек үзәге директоры тарафыннан билгеләнә.

### 4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру тәртибе һәм аларның ешлыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына контрольлек тәртибе һәм формалары

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итү Министрлык тарафыннан планлы (планнан тыш) күчмә (документар) тикшерүләр

үткәрү юлы белән башкарыла.

Контроль тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырылганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгатенә бәйле мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүне контрольдә тоту кысаларында, эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү өлешендә дәүләт гарантияләреннән тыш, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә күзәтчелек һәм контрольдә тоту вәкаләтләрен үтәү кысаларында Министрлык башкара.

### 4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органдагы вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре, халыкның мәшгульлек үзәге һәм Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

### 4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да, контрольлек тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне сыйфатлый торган нигезләмәләр

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәге эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлегендә мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ санлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Эш бирүче халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи заты (белгече) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә шикаять бирергә хокуклы.

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл

кылмавына) шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

5.2. Эш бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

эш бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматлар тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны эш бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә эш бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи зат (белгеч) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре җибәргән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартылган очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда эш бирүчедән, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган (учреждение), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты (белгече) яисә дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта, күпфункцияле

үзәк, «Интернет» челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru) файдаланып, Татарстан Республикасы порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм портал (https://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.https://www.gosuslugi.ru

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең (http://mfc16.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. Органга (учреждениегә) алынган шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи затның (белгечнең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи затның (белгечнең) яисә граждан хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең яки хезмәткәренең исеме;
- мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;
- дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;
- мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи зат (белгеч) яисә дәүләт хезмәткәре карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Эш бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән

чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, эш бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.7. Әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, эш бирүчегә язма рәвештә яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, бу Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән эш бирүчегә җавапта, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган орган (учреждение), КФУ тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында алга таба эш бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән эш бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең) шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи заты, халыкның мәшгульлек үзәге белгече булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.11. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ санлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр
сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү административ
регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна оешмасы ____________________
________________________________________________________________________»

Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында 20___ елның «_____»
______________ санлы карар

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20___ елның «___» ____________ № ____ боерыгы белән расланган Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентының 2.8 пункты нигезендә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартырга____________________________
___________________________________________.

(эш бирүченең исеме)

Баш тарту сәбәбе:
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе
________________________________________
(ФИА, имза)

Карарны алды
________________________________________
(ФИА, имза)

«_____»________________20___ел.

Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр
сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү административ
регламентына 2 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна оешмасы ____________________
_____________________________________________________________________»

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
(булган очракта) тулысынча күрсәтелә)
яши торган адрес: ___________________________________________________
_____________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
_____________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ атамасы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы,
_____________________________________________________________________,
документны биргән орган атамасы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________,
кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алу өчен гражданнар кандидатуралары исемлегендә җибәрелгән «___» ________________ 20__ел.
Кирәкле хезмәткәрләр сайлау өчен гражданнар кандидатураларының үзгәртеп рәсмиләштерелгән исемлеген алуга риза
_____________________________________________________________________
(язмача, электрон почта, ТР Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетка)

«___» ____________ 20__ел. ________________________ ____________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)

Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр
сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү административ
регламентына 3 нче кушымта

Эш бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен теркәү журналы

| т/с | Мөрәҗәгать итү датасы | Оешма атамасы | Адрес | Мөрәҗәгать итү сәбәпләре | Мөрәҗәгать итү нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Эш бирүчеләргә кирәкле
хезмәткәрләр сайлап алуда
булышлык күрсәтү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтү административ
регламентына 4 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«Халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна оешмасы ___________________
_____________________________________________________________________»

Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында 20____ елның «______» __________________ карар

____________________________________ мөрәҗәгать итүенә бәйле рәвештә
(Физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта),
юридик зат – мөрәҗәгать итүченең атамасы)
Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында _____ елның _________________ № ________ гариза

нигезе: ____________________________________________________________
_____________________________________________________________________

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, чөнки:
1. ______________________________________________________________
2. ______________________________________________________________

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе _______________________________
(ФИА, имза)

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече __________________________________
(ФИА, имза)

Карарны алды

_________________________________
(ФИА, имза)

«_____»________________20___ел.

Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр
сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү административ
регламентына (белешмәлек) кушымта

**Эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр**

1. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт оешмалары

| Халыкның мәшгульлек үзәге атамасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| «Азнакай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (85592) 7-57-90 | Czn.Aznakaevo@tatar.ru |
| «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84344) 2-73-94 | Czn.Aksubaevo@tatar.ru |
| «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (85552) 3-09-83 | Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| «Алексеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84341) 2-54-00 | Czn.Alekseevskoe@tatar.ru |
| «Әлки районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84346) 2-15-89 | Czn.Alkeevo@tatar.ru |
| «Әлмәт шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (8553) 32-34-99 | Czn.Almet@tatar.ru |
| «Апас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84376) 2-12-15 | Czn.Apastovo@tatar.ru |
| «Арча районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84366) 3-17-33 | Centr.Arskiy@tatar.ru |
| «Әтнә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84369) 2-16-51 | Czn.Atnya@tatar.ru |
| «Баулы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (85569) 5-62-29 | Czn.Bavly@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| «Балтач районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84368) 2-44-19 | Czn.Baltasi@tatar.ru |
| «Бөгелмә шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (85594) 4-17-60 | Czn.Bugulma@tatar.ru |
| «Буа шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84374) 3-13-73 | Czn.Buinsk@tatar.ru |
| «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84379) 2-18-99 | Czn.V-uslon@tatar.ru |
| «Биектау районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84365) 3-16-17 | CZN.VGora@tatar.ru |
| «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84375) 2-25-87 | Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| «Алабуга шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (85557) 7-58-58 | Czn.Elabugi@tatar.ru |
| «Зәй шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (85558) 7-15-43 | Czn.Zainsk@tatar.ru |
| «Зеленодольск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84371) 5-64-90 | Czn.Zdol@tatar.ru |
| «Кайбыч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84370) 2-12-60 | Czn.Kaibicy@tatar.ru |
| «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84364) 2-67-54 | Czn.Kukmor@tatar.ru |
| «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84378) 2-48-12 | д. 35, Laish.Czn@tatar.ru |
| «Лениногорск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (85595) 5-59-70 | Czn.Leninogorsk@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| «Мамадыш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (85563) 3-35-57 | Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Әгерже районы филиалы | (85549) 2-23-57 | Czn.Men@tatar.ru |
| «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (85551) 2-31-73 | Centr.Agryzskiy@tatar.ru |
| «Мөслим районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (85555) 3-23-80 | Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Тукай районы филиалы | (85556) 2-55-80 | Czn.Muslymovo@tatar.ru |
| «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Аланы бүлеге | (8552) 52-42-68 | Chelny.CZN@tatar.ru |
| «Яңа Чишмә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (8552) 52-96-97 | Czn.Tukaev@tatar.ru |
| «Нурлат ш. халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (8555) 42-40-79 | Czn.Nk@tatar.ru |
| «Питрәч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (8555) 33-98-61 | Czn.Nk@tatar.ru |
| «Балык Бистәсе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84348) 2-30-42 | Czn.Novoshesh@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84345) 2-46-30 | Czn.Nurlat@tatar.ru |
| «Сарман районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84367) 3-04-84 | CentrZan.Pestr@tatar.ru |
| «Спас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84361) 2-21-81 | Czn.R.sloboda@tatar.ru |
| «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Тамагы районы филиалы | (84362) 2-28-15 | SZN.Saby@tatar.ru |
| «Теләче районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (85559) 2-42-62 | Czn.Sarmanovo@tatar.ru |
| «Чирмешән районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84347) 3-07-72 | Czn.Bolgar@tatar.ru |
| «Чистай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84373) 2-63-29 | Czn.Tetyushi@tatar.ru |
| «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84377) 2-14-67 | Filial.K-uste@tatar.ru |
| «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Совет районы филиалы | (84360) 2-13-51 | Czn.Tyulyachi@tatar.ru |
| «Авиатөзелеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84396) 2-54-59 | Czn.Cheremshan@tatar.ru |
| «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (84342) 5-13-34 | Czn.chist@tatar.ru |
| «Киров районы халыкның мәшгульлек | (85593) | Czn.Yutazy@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| үзәге» дәүләт казна учреждениесе | 2-98-00 | |
| «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (843) 562-48-33 | Czn.g_Kazan@tatar.ru |
| «Яңа Савин районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (843) 273-85-03 | CZN/Sovetskiy@tatar.ru |
| «Идел буе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | (843) 537-86-00 | Czn.Avia@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфаның атамасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-03 | Klara.Tazetdinova@tatar.ru |
| Эш белән тәэмин итүдә актив сәясәт чараларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы | 557-20-73 | Elena.Kibardina@tatar.ru |
| Хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек бүлеге | 557-21-58 | Azat.Ayupov@tatar.ru |